Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Новопольского сельского поселения**

Свободы ул, 39 п.Новопольский,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты**
Иреклек ур., 39 Новополька п,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
КАРАР

28 марта 2019 года № 40

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районының
Новополька авыл җирлегендә җирләү
буенча гарантияләнгән хезмәтләр
исемлеге нигезендә хезмәт күрсәтүләр
бәяләрен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирләү һәм күмү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында “Җирләү һәм күмү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елда түләүләрне, ярдәмнәрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелүче хезмәтләрнең бәясен Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлегендә 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә 5946,47 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Зеленодол муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча: Новополька бистәсе, Азатлык урамы, 39 йорт, Үрнәк бистәсендә Магазин янындагы мәгълүмати такта, Үзәк урам, 53а йорт, Азатлык урамы, 24 йорт Новополька бистәсенең мәгълүмати тактасы, Грузин бистәсенең Ветераннар урамы мәгълүмати тактасы, Красницкий бистәсенең Тынычлык урамы, 3 йорт мәгълүмати тактасы, Дубровка бистәсенең Дуслык урамы 1 йорт мәгълүмати тактасы, Новочувашский бистәсенең Яшел урам, 1 йорт мәгълүмати тактасы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үземдә калдырам.

Новополька авыл
җирлеге башлыгы Н.Ю.Якупов

Зеленодол муниципаль районының
Новополька авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 28 мартындагы
40 номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең атамасы** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 87,88 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3240,53 |
| 3. Вафат булучының җәсадын (калган өлешен) зиратка илтү | 923,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1694,94 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Зеленодол муниципаль районының
Новополька авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 28 мартындагы
40 номерлы карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең атамасы** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 87,88 |
| 2. Кәфенләү | 572,51 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2668,02 |
| 4. Вафат булучының җәсадын (калган өлешен) зиратка илтү | 923,12 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1694,94 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |